СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский",
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGjr.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Боерык

№ 2-7 — «03 » марта 2016 года

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының 23.03.2015 № ПУ-308 Указын үтәү йөзеннән, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 01 июлендәге 821 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль район Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 7-16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның " б " пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

муниципаль хезмәткәрнең "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" Федераль закон (алга таба - "Аерым

категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, кулга алынуга һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау хакында гаризасы, үз территориясендә счетлары (кертемнәре) булган әлеге чит дәүләт законнары нигезендә чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан салынган кулга алынуга, боерыклар тыюга бәйле рәвештә чит ил банкында һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары, яисә аның иренең яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка хәлләр белән бәйле булган акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны гамәлгә ашыру.

1.2. 14 статьяның «д» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

д) "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлешенә һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясына ярашлы рәвештә җирле үзидарә органына җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан белән эшләрне башкаруга хезмәт яки гражданлык-хокукый килешү төзү турында коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмага хәбәр итү (әгәр әлеге оешманың муниципаль идарәсе аерым функцияләре аның вазифа (хезмәт) бурычларына керсә) , комиссия тарафыннан әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керүдән баш тартылган яки мондый гражданга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга ризалык бирү мәсьәләсе комиссия тарафыннан җирле үзидарә органында вазыйфа биләгәндә башкарыла торган вазыйфалар каралмаган очракта.

1.3. 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

17. Комиссия утырышы хезмәт тәртибе таләпләренең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затка, яисә вакытлыча аның вазыйфаларын башкаручы затка, карата каралганда муниципаль хезмәткәр катнашында үткәрелә. Муниципаль хезмәткәрнең яисә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче гражданның күрсәтелгән сорауны аның катнашыннан башка карау турында язма үтенече булганда, комиссия утырышы аннан башка уздырыла. Әгәр муниципаль хезмәткәр (аның вәкиле) комиссия утырышына килмәсә һәм муниципаль хезмәткәрнең әлеге мәсьәләне аннан башка гына карау турында язмача үтенече булмаса, мәсьәләне карау кичектерелә. Муниципаль хезмәткәр җитди сәбәпсез икенче тапкыр килмәгән очракта, комиссия әлеге мәсьәләне муниципаль хезмәткәрдән башка гына карау турында Карар кабул итә ала. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан (аның вәкиле) комиссиясе утырышына килмәгән очракта, күрсәтелгән граждан яшәү урынын алмаштырган һәм комиссия утырышын уздыру датасы турында аңа мәгълүмат җиткерү буенча барлык чаралар күрелгән очракта, комиссия

әлеге мәсьәләне күрсәтелгән граждан булмаганда карау турында карар кабул итәргә мөмкин.

1.4. Түбәндәге эчтәлектәге 23.2 статьяны кертергә:

Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган шартларның объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган шартларның объектив һәм нигезле булуын танырга. Бу очракта комиссия муниципаль орган җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга киңәш итә.

1.5. 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

24. Әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы «а», «б», «г» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булганда, комиссия әлеге Нигезләмәнең 20-23, 23.1, 23.2 һәм 24.1 пунктларында каралганнан башка карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы протоколында чагылдырылырга тиеш.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы В.А.Гыйззәтуллинага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гыйззәтуллина